РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.03.2020 № 360-п

Спорт чараларында катнашучыларны һәм
хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан
тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибен
һәм нормаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, спортны үстерүгә ярдәм итү, югары спорт нәтиҗәләренә ирешү өчен спортчыларның эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибен һәм нормаларын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибен һәм нормаларын раслау турында” 2016 елның 7 маендагы 565-п номерлы карары;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 маенда кабул ителгән 565-п номерлы карары белән расланган спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибе һәм нормаларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2016 елның 18 октябрендә кабул ителгән 1280-п номерлы карары;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 маенда кабул ителгән 565-п номерлы карары белән расланган спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибе һәм нормаларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2017 елның 26 сентябрендә кабул ителгән 1235-п номерлы карары;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 7 маенда кабул ителгән 565-п номерлы карары белән расланган спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибе һәм нормаларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2017 елның 19 декабрендә кабул ителгән 1568-п номерлы карары;

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибе һәм нормалары**

1. **Гомуми нигезләмәләр**

**1.1**. Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибе һәм нормалары агымдагы елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетында каралган акчалар хисабына уздырыла торган чараларга кагыла.

**1.2.** Спорт чараларына ярышлар (чемпионатлар, беренчелекләр, кубокларга ярышлар, спартакиадалар, фестивальләр, турнирлар, регатлар, матч очрашулары, слетлар) һәм укыту-өйрәтү (күнекмә) җыеннары керә.

**1.3.** Спорт чараларында катнашучыларга спортчылар, тренерлар, спорт судьялары, хезмәт күрсәтүче персонал (механиклар, хореографлар, командалар администраторлары, аккомпаниаторлар һ.б.) һәм спорт төрләре буенча ярышлар кагыйдәләре һәм ярышлар уздыру турында нигезләмәләр (регламентлар) белән каралган башка белгечләр керә.

**1.4.** Катнашучыларны спорт чараларына җибәрү оешмаларның, аларны үткәрүчеләрнең рәсми чакыруы яисә ярышлар үткәрү турындагы нигезләмә, агымдагы елга (ай, атнага) расланган спорт чаралары планы - календаре нигезендә гамәлгә ашырыла.

**1.5.** Спорт чараларын үткәрүче оешмаларга Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәгариф бүлеге), Саба муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган башка органнар, учреждениеләр һәм оешмалар, спорт җәмгыятьләре һәм ведомстволары, спорт төрләре буенча иҗтимагый спорт берләшмәләре (федерацияләр, ассоциацияләр, союзлар, клублар һ.б.), профессиональ спорт клублары, спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү юнәлешендәге оешмалар һәм учреждениеләр керә.

**2. Акчаларны тоту тәртибе.**

**2.1.** Спорт чараларын уздырганда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр раслана:

– Ярышлар үткәрү турында нигезләмәләр (регламентлар), аларның тәртибе, чит ил делегацияләренең килү программалары, башка регламентлаштыручы документлар;

– спорт чараларында катнашучыларның санын, аларны үткәрү срокларын һәм чыгымнарны исәпләүне үз эченә алган чыгымнар сметасы.

**2.2.** Туклануга, фармакология һәм башка препаратларга һәм чараларга чыгымнар, судьялык өчен түләү, спортчыларга, тренерларга һәм башка белгечләргә акчалата премияләр түләү, хезмәт күрсәтүче персоналга һәм белгечләргә

башкарылган эш өчен түләү билгеләнгән нормалар нигезендә башкарыла.

**2.3**. Чит ил спорт делегацияләрен кабул итү һәм аларга хезмәт күрсәтү, район территориясендә халыкара спорт чараларын уздыру чыгымнары, муниципаль район Башкарма комитеты тарафыннан төзелгән килешүләр нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең тиешле күрсәтмәсе белән расланган, чит ил делегацияләрен һәм аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә акча тотуның гамәлдәге нормаларына туры китереп башкарыла.

**2.4.** Спорт чаралары уздырыла торган урынга бару юлында катнашучыларның барлык категорияләренә дә район территориясендә билгеләнгән тәүлеклек түләнә, чаралар уздырылган көннәрдә катнашучыларның барлык категорияләре дә ашау белән тәэмин ителә.

**2.5**.Катнашучыларны, тренерларны, судьяларны һәм белгечләрне командировкага җибәрү чыгымнарын каплау хезмәт командировкалары өчен билгеләнгән нормалар буенча башкарыла.

**2.6.** Спорт корылмаларын һәм җиһазларын арендалау чыгымнары, транспорт, почта-телеграф, типография, канцелярия һ.б.чыгымнар, чаралар уздырылган көнгә гамәлдә булган бәяләр яки килешү бәяләре буенча спорт чараларын иң нәтиҗәле үткәрүне һәм чараларны куллануны тәэмин итә торган күләмнәрдә башкарыла.

**2.7.** Спорт чараларына хезмәт күрсәтүгә җәлеп ителгән белгечләрнең (медицина хезмәткәрләренең, эшчеләрнең, радистларның, рәссамнарның, машинистларның, моторчыларның һ.б.) хезмәте өчен түләү Россия Федерациясенең хезмәт турындагы законнары нигезендә башкарыла.

**2.8.** Спорт чараларын бюджеттан тыш акчалар, шулай ук иганәчеләр акчалары, катнашучы оешмалар түләүләре һәм башка җәлеп ителгән чыганаклар хисабына үткәрүче оешмалар әлеге карарда билгеләнгән нормадан тыш катнашучыларга түләүләрне арттырырга хокуклы.

## 3. Спорт чараларын финанслау тәртибе.

**3.1**. Чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар һәм аларга тиңләштерелгән башка ярышларны оештырганда чыгымнарны түбәндәге оешмалар каплый:

– спорт корылмаларын һәм җиһазларын арендалау, судьялык өчен түләү, җиңүчеләрне бүләкләү, хезмәт күрсәтүче персоналны тоту, почта-телеграф, типография, канцелярия, транспорт һәм башка хезмәтләр, катнашучыларны ашату һәм урнаштыру буенча - ярышларны оештыра торган оешмалар;

– катнашучыларны командировкага җибәрү ( юл йөрү өчен һәм тәүлеклек юл өчен түләү, ярыш көннәрендә ашату һәм урнаштыру) буенча - ярышларда катнашучы оешмалар.

**3.2.** Укыту-өйрәтү җыеннарын оештырганда чыгымнарны түбәндәге оешмалар каплый:

– җыелма командалар әгъзаларын үзәкләштереп әзерләү, юлда йөрү һәм тәүлеклек юл өчен түләү буенча - җыеннарны оештыра торган оешмалар;

– спортчыларның җыелма командаларына кандидатлар (стажерлар) туплау, аларны җыеннар уза торган җиргә китерү һәм кире кайтару, яшәү урыны буенча спортчыларны әзерләү буенча - физкультура-спорт оешмалары.

**3.3.** Спорт чаралары аларда катнашучы оешмаларның акчаларын кулланып, заявка (старт) түләүләрен алу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта чыгымнар составы һәм заявка түләүләре күләме ярышларны оештыручы оешма тарафыннан раслана.

**3.4.** Әлеге кушымтага кертелмәгән ярышлар үткәрүгә бәйле барлык чыгымнар күрсәтелә торган хезмәтләрне тулырак расшифровкалау белән белешмәләр яки бәя бирү буенча исәпләнә.

## 4. Спорт чараларын уздырганда спортчыларны, тренерларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны, белгечләрне ашау һәм яшәү урыны белән тәэмин итүгә чыгымнар нормалары.

| №№ пп | Спорт чараларын үткәрү территориясе | Бер катнашучыга чыгымнар нормасы-сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Саба районы территориясендә туклану | 300 гәкадәр |
| | ТР территориясендә туклану | 500 гә кадәр |
| | РФ территориясендә туклану | 500 гә кадәр |
| | ТР һәм РФ территориясендә министрлыклар һәм башка оешмаларның боерыклары, нигезләмәләре, регламентлары һәм хатлары нигезендә туклану | 900 гә кадәр |
| 2 | ТР территориясендә яшәү | 850 гә кадәр |
| | Министрлыкларның һәм башка оешмаларның боерыклары, нигезләмәләре, регламентлары һәм хатлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә яшәү | 1000 гә кадәр |
| | ТР чикләреннән тыш РФдә яшәү | 2000 гә кадәр |
| | Чит илдә яшәү | 5 000 гә кадәр |
| 3 | Саба районы территориясендә укыту-өйрәтү җыеннары үткәрүче белгечләргә һәм тренерларга түләү | 2000 гә кадәр |

## 5. Спорт ярышларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләүләр күләме.

**5.1**. Судьяларга спорт чараларын гадел хөкем итү хезмәте өчен түләү түбәндәге күләмнәрдә башкарыла*:

| №№ пп | Спорт чаралары дәрәҗәсе | Вазыйфа | Бер катнашучыга чыгымнар нормасы (көнгә сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | Район ярышлары | Ярышларның баш судьясы (директоры, җитәкчесе) | 800 гә кадәр |
| | | Барлык дәрәҗәләрдәге, категорияләрдәге судьялар | 300 гә кадәр |
| | | Медицина хезмәте күрсәтү | 300 гә кадәр |
| | | Уеннарга хезмәт күрсәтү | 300 гә кадәр |
| 2 | Республика ярышлары, Идел буе федераль округы дәрәҗәсендәге ярышлар, Россия ярышлары, халыкара ярышлар | Ярышларның баш судьясы (директоры, җитәкчесе) | 6000 гә кадәр |
| | | Судья | 2000 гә кадәр |
| | | Медицина хезмәте күрсәтү | 2000 гә кадәр |
| | | Уеннарга хезмәт күрсәтү | 2000 гә кадәр |

* Искәрмә: судьялар хезмәте өчен республика (шул исәптән зона), Идел буе федераль округы, РФ дәрәҗәсендә түләү, судьяларның суммасы регламентта (нигезләмәдә) күрсәтелсә, әлеге ярышларны үткәрү турындагы регламент (нигезләмә) буенча башкарыла.

1. Түләү күләме ярышларның бер көненә хезмәт күрсәтү өчен каралган, спортның команда уен төрләреннән тыш, бер уенга хезмәт күрсәтү өчен түләүләр

башкарылырга мөмкин (футбол, шайбалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, чирәмдәге хоккей, туплы хоккей, бейсбол, регби һ.б.).

2. Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этапларында судьяларны матди тәэмин итү (яшәү, судьялык өчен түләү) судьялар эшенең барлык чоры дәвамында түбәндәге гомуми дәвамлылык белән гамәлгә ашырыла:

- баш судья, баш сәркатип - 5 көнгә кадәр;
- баш судья урынбасары, баш судья-сәркатип урынбасары - 3 көнгә кадәр.

3. Федерацияләр һәм спорт чаралары үткәрүче башка оешмалар үз, иганәчелек акчалары, шулай ук заявка түләүләре хисабына спорт судьяларына билгеләнгән түләү күләменә өстәмә түләү башкарырга хокуклы.

4. Рәсми халыкара ярышларга хезмәт күрсәтүче спорт судьяларына түләүләр күрсәтелгән ярышлар Регламентында каралган тәртиптә һәм күләмнәрдә башкарылырга мөмкин..

5. Судья коллегияләренең (бригадаларның) саны спорт төрләре буенча ярышлар уздыру кагыйдәләре һәм нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.

6. Халыкара ярышларны, Россия чемпионатларын һәм кубокларын оештыруны һәм уздыруны тикшереп тору өчен, иң квалификацияле судьялар һәм белгечләр арасыннан, уеннарның төп судьялары өчен каралган күләмнәрдәге түләү белән, инспектор яисә техник делегатлар билгеләнергә мөмкин.

7. Халыкара федерация тарафыннан билгеләнгән чит ил техник делегатлары һәм судьяларына халыкара категорияле судьялар өчен каралган күләмнәрдә түләнә.

## 6. Спорт чараларында җиңүчеләргә һәм призерларга бирелә торган истәлекле бүләкләр һәм махсус истәлекле бүләкләр бәясе күләме.

| № п/п | Спорт чаралары дәрәҗәсе | Алын ган урын | Бүләкләр бәясе - сумнарда | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Команда (бер команда әгъзасына исәплэгәндә) | Шәхси |
| 1. | Район дәрәҗәсендәге ярышларда призлы урыннар алган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 1000гә кадәр | 3500 гә кадәр |
| | | II | команданың бер әгъзасына 900гә кадәр | 3000 гә кадәр |
| | | III | команданың бер әгъзасына 800гә кадәр | 2500 гә кадәр |
| 2. | Татарстан Республикасы беренчелекләрендә, чемпионатларында, Кубогында призлы урыннар яулаган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 2000гә кадәр | 3000 гә кадәр |
| | | II | команданың бер әгъзасына 1500гә кадәр | 2500 гә кадәр |
| | | III | команданың бер әгъзасына 1000гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| 3. | Барлык дәрәҗәдәге спартакиадаларда призлы урыннар алган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 2000гә кадәр | 2000 гә кадәр |
| | | II | команданың бер әгъзасына 1500гә кадәр | 1500 гә кадәр |
| | | III | команданың бер әгъзасына 1000гә кадәр | 1000 гә кадәр |
| 4. | Идел буе федераль округы дәрәҗәсендә призлы урыннар алган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 3000гә кадәр | 4000 гә кадәр |
| | | II | команданың бер әгъзасына 2500гә кадәр | 3500 гә кадәр |
| | | III | команданың бер әгъзасына 2000гә кадәр | 3000 гә кадәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Беренчелекләрдә, чемпионатларда, Россия Кубогында призлы урыннар яулаган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 10000гә кадәр | 10000 гә кадәр |
| | | II | команданың бер әгъзасына 8000гә кадәр | 8000 гә кадәр |
| | | III | команданың бер әгъзасына 6000гә кадәр | 6000 гә кадәр |
| 5.1 | Саба муниципаль районы территориясендә уздырыла торган беренчелекләрдә, чемпионатларда, Россия Кубогында призлы урыннар яулаган спортчылар | I | команданың бер әгъзасына 15000гә кадәр | 15000 гә кадәр |
| | | II<br>III<br>IV<br>V<br>VI | команданың бер әгъзасына 13000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 10000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 5000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 3000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 2000гә кадәр | 13000 гә кадәр<br>10000 гә кадәр<br>5000 гә кадәр<br>3000 гә кадәр<br>2000 гә кадәр |
| 6. | Беренчелекләрдә, чемпионатларда, Европа Кубогында призлы урыннар яулаган спортчылар | I<br>II<br>III | команданың бер әгъзасына 20000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 15000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 10000гә кадәр | 20000 гә кадәр<br>15000 гә кадәр<br>10000 гә кадәр |
| 7. | Беренчелекләрдә, чемпионатларда, Дөнья Кубогында призлы урыннар яулаган спортчылар | I<br>II<br>III | команданың бер әгъзасына 30000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 25000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 20000гә кадәр | 30000 гә кадәр<br>25000 гә кадәр<br>20000 гә кадәр |
| 8. | Олимпия, Паралимпия, Сурдлимпия уеннарында призлы урыннар яулаган спортчылар | I<br>II<br>III | команданың бер әгъзасына 40000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 35000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 30000гә кадәр | 40000 га кадәр<br>35000 гә кадәр<br>30000 гә кадәр |
| 9. | Район, ТР, РФ һәм чит илләрдә үткәрелә торган халыкара турнирлар | I<br>II<br>III | команданың бер әгъзасына 3000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 1500гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 1000гә кадәр | 3000 гә кадәр<br>1500 гә кадәр<br>1000 гә кадәр |
| 10. | Спортчыларны Россия беренчелеге һәм чемпионаты финалына чыгара торган турнирлар | I<br>II<br>III | команданың бер әгъзасына 5000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 4000гә кадәр<br>команданың бер әгъзасына 3000гә кадәр | 5000 гә кадәр<br>4000 гә кадәр<br>3000 гә кадәр |
| 11 | Район смотр-конкурслары,призлар бирү белән җәйге һәм кышкы спартакиадалар | I<br>II<br>III | командага 20000гә кадәр<br>командага 150000гә кадәр<br>командага 10000гә кадәр | 30000 гә кадәр<br>25000 гә кадәр<br>20000 гә кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Спортчыларны ТР Беренчелекләренә, Чемпионатларына һәм республика дәрәҗәсендәге Спартакиадаларга (спортчы биләгән урынга карап) әзерләгән тренерлар | I<br>II<br>III | 3000 гә кадәр<br>2000 гә кадәр<br>1000 гә кадәр |
| 13 | Спортчыларны Идел буе федераль округы дәрәҗәсендәге ярышларга әзерләгән тренерлар (спортчы биләгән урынга карап) | I<br>II<br>III | 4000 гә кадәр<br>3000 гә кадәр<br>2000 гә кадәр |
| 13.1 | Чемпионат уеннарында, ирләр командалары арасында шайбалы хоккей буенча Татарстан Республикасы Беренчелеге һәм Кубогы һәм ирләр командалары арасында Төнге Хоккей Лигасы 18+ уеннарында җиңү өчен | Уенда җиңү өчен | 500 сумга кадәр |
| 14. | Спортчыларны Россия Беренчелегенә һәм Россия Чемпионатына әзерләгән тренерлар (спортчы биләгән урынга карап) | I<br>II<br>III | 5000 гә кадәр<br>4000 гә кадәр<br>3000 гә кадәр |
| 15. | Спортчыларны Европа Беренчелегенә әзерләгән тренерлар (спортчы биләгән урынга карап) | I<br>II<br>III | 8000 гә кадәр<br>7000 гә кадәр<br>6000 гә кадәр |
| 16. | Спортчыларны Беренчелеккә һәм Дөнья Чемпионатына әзерләгән тренерлар (спортчы биләгән урынга карап) | I<br>II<br>III | 10000 гә кадәр<br>9000 гә кадәр<br>8000 гә кадәр |
| 17. | Спортчыларны Олимпиадага, Паралимпиадага, Сурдлимпиадага әзерләгән тренерлар (спортчы алган урынга карап) | I<br>II<br>III | 15000 гә кадәр<br>14000 гә кадәр<br>13000 гә кадәр |
| 18 | Әлеге тәртип һәм нормаларның 13 пунктында санап үтелгән иң яхшы спортчыларга, тренерларга һәм башка белгечләргә | | 1000 гә кадәр |
| 19 | Физик культураны үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы хаты белән бүләкләү* | | 3000 гә кадәр |
| 20 | Физик культураны үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Рәхмәт хаты белән бүләкләү* | | НДСны исәпкә алмыйча 10000 гә кадәр |
| 21 | Физик культураны үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мактау грамотасы белән бүләкләү* | | НДСны исәпкә алмыйча 20000 гә кадәр |

Искәрмә:

1. Спорт ярышларында җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләгәндә югарыда күрсәтелгән күләмнәргә туры китереп акча белән түләү рөхсәт ителә.

2. Иң яхшы спортчылар, тренерлар һәм башка белгечләр (“Җиңүгә омтылыш өчен”, “Иң яхшы техника өчен”, “Чемпион әзерләгән өчен” һ.б.) өчен аерым ярышлар нәтиҗәләре буенча махсус призлар күләме тиешле дәрәҗәдәге ярышларда 3 урын өчен приз бәясеннән югарырак билгеләнми.

3. Комплекслы ярышлар (спартакиадалар, уеннар) нәтиҗәләре буенча бүләкләгәндә призлар бәясе ярышларда җиңү өчен бирелә торган призлар бәясе күләменә һәм бер дәрәҗәгә күтәрелә.

## 7. Саба муниципаль районы җыелма командаларын фармакология әйберләре, тернәкләндерү әйберләре, витаминнар һәм аксым препаратлары, гомуми дәвалау билгеләнешендәге медикаментлар, яра бәйли торган әйберләр белән тәэмин итүгә чыгымнар нормалары.

| №№ пп | Спорт чаралары дәрәҗәсе | Бер катнашучыга чыгымнар нормасы-сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе территориясендә үткәрелә торган халыкара ярышлар | 150 гә кадәр |
| 2. | Спорт төрләре буенча Бөтенроссия һәм зона ярышлары | 120 гә кадәр |
| 3. | Укыту-өйрәтү (күнекмә) җыеннары | 100 гә кадәр |

Искәрмә. Бушлай фармакология әйберләре, аксым-глюкоза препаратлары һәм витаминнар белән түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1. Ярышларда катнашучылар - аларда фактик катнашу көннәрендә;
2. Укыту-өйрәтү (күнекмә) җыеннарында катнашучылар – җыеннар үткәрелгән көннәрдә.

## 8. Укыту-өйрәтү җыеннары классификациясе

| №№ пп | Укыту-өйрәтү җыеннары атамасы | Җыен дәвамлылыгы | Катнашучыларның максималь составы |
|---|---|---|---|
| | 1. Ярышларга әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | | |
| 1.1. | Халыкара ярышларга әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 24 көнгә кадәр | ике составтан артык түгел |
| 1.2. | Россия Федерациясе Беренчелеге һәм Кубогы чемпионатларына, ярышларына әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 2 4 көнгә кадәр | бер ярымнан артык булмаган состав |
| 1.3. | Башка бөтенроссия ярышларына әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 18 көнгә кадәр | - |
| 1.4. | Район ярышларына әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 20 көнгә кадәр | - |
| | 2. Махсус укыту-өйрәтү җыеннары | | |
| 2.1. | Гомуми физик әзерлек буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 18 көнгә кадәр | бер составтан артык түгел |
| 2.2. | Медицина тикшерүе үткәрү буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 7 көнгә кадәр | бер составтан артык түгел |
| 2.3. | Тернәкләндерү буенча укыту-өйрәтү җыеннары | 10 көнгә кадәр | - |

## 9. Канцелярия товарлары һәм кулланыла торган материаллар сатып алуга чыгымнар нормалары

| №№ пп | Спорт чараларының атамасы | Көненә бер кешегә бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Халыкара ярышлар (Россия территориясендә үткәрелә) | 100 гә кадәр |
| 2. | Бөтенроссия һәм физкультура-массакүләм чаралар | 50 гә кадәр |

## 10. Электрон җиһазларны һәм контроль-үлчәү приборларын арендага алу бәясе

| №№ пп | Атамасы | Бер көнгә аренда бәясе сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Компьютер белән тәэмин итү | 5000 гә кадәр |
| 2. | Электрон судьялык-мәгълүмат аппаратурасы:<br>көрәш төрләре өчен:<br>- берьяклы;<br>- ике яклы;<br>- спортның уен төрләре өчен | <br><br><br>3000 гә кадәр<br>5000 гә кадәр<br>5000 гә кадәр |

Искәрмә.

1. Күрсәтелгән таблицага кермәгән электрон җиһазлардан һәм контроль-үлчәү приборларыннан файдаланган өчен аренда түләве күрсәтелә торган хезмәтләрне тулырак расшифровкалау белән белешмәләр яки бәя бирү буенча исәпләнә.

2. Электрон судьялык-мәгълүмат аппаратурасы көрәш төрләре өчен бер келәмгә, спортның уен төрләре өчен бер мәйданчыкка караган.